Туган телем - иркә гөлем, киңдер сиңа күңел түрем...

Күмәк көч

ГОМУМИ РАЙОН
ТАТАР ГАЗЕТАСЫ
1930 елдан чыга.
Бәясе ирекле
№ 9 (106101)
Чәршәмбе,
1 март 2017 ел.
(Атнага бер тапкыр чыга)

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫЛАР: 1. УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ ХӨКҮМӘТЕ (432017, Ульяновск шәһәре, Ленин мәйданы, 1)2. "ИСКЕ КУЛАТКЫ РАЙОНЫ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРЛӘШМӘСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ (433940, Ульяновск өлкәсе, Иске Кулаткы эшчеләр бистәсе, Пионерская урамы, 30)

Ремонтны оешкан төстә

Менә яз да килеп җитте. Март аеның тамчылары авыл хуҗалыгы эшчәннәренә язгы чәчүгә әзерлекләре турында искә төшерә, сыман. Хуҗалык җитәкчеләре дә, механизаторлар да моның турында аңлап, техникаларга ремонтны дәвам итәләр.

Бу эшләр ИП “Богданов Р. Ә.” хуҗалыгында да тиешле дәрәҗәдә алып барыла.

- Механизаторлар: Рамил Мусиев, Наил Абдюков, Рәшит Юнусов, Шамил Ханбиков кыш барышында өч “Т- 150” тракторын җайладылар. Аларның тырышлыгы белән бер “Т-150” тракторына “ЯМЗ” маркалы двигатель куелды,- дип сөйли хуҗалык җитәкчесе Расим Әхмәдиевич Богданов. - Кыр эшчәннәре шулай ук февраль аенда 100 тырмага ремонт ясадылар. Гомумән әйткәндә, техникаларыбыз әзер. Кар китүгә чәчкечләргә вак-тәяк ремонт эшләре генә башкарасы кала. Механизаторларыбыз техникаларны ремонтлауга зур җаваплылык белән карыйлар. Аларның тырышлыгы белән язгы чәчүне дә уңышлы гына үткәрергә планлаштырабыз.

Җитәкче сүзләренчә, механизаторларның җаваплылыгына ышанып була. Чөнки алар бер-берсе белән нык элемтәдә булып, аңлашып озак еллар хезмәт итәләр.

2016 елда ИП “Богданов Р. Ә.” хуҗалыгы 925 гектарда уҗым культуралары чәчеп калдырды. Аларның торышы да яхшы хәлдә. Ел уңай килгәндә зур уңыш алырга өметләр бар. Үткән елда туңга сөрү планы да үтәлде. Кыр эшчәннәре быел 890 гектар эшкәртелгән мәйданга 40 гектар - арпа, 60 гектар - солы, 74 гектар - сафлор, 400 гектарда көнбагыш һәм башка сабан культураларын чәчергә планлаштыралар. Хуҗалыкта чәчү орлыклары җитәрлек һәм мөмкин кадәр җиргә ашлама да кертеләчәк. Кыр эшләрен башлап җибәрергә 5 тонна дизель ягулыгы бар һәм якын арада ул тагын кайтарылачак.

Гомумән, районыбызда техниканы ремонтлау буенча да уңай картина күзәтелә. Хуҗалыкларда төрле маркалы 224 трактор бар, шуларның 204 се (91,1%) кырга чыгарга әзер. Шулай ук чәчү агрегатларына тиешле ремонт эшләре дә башкарылган. Язгы кыр эшләренә 361 тонна дизель ягулыгы кирәк булачак һәм аның 328 тоннасы бар инде. Чәчү орлыклары да җитәрлек дәрәҗәдә, барлыгы 2185 тонна, яисә 100 процент тәшкил итә.

Рөстәм АРИФУЛЛИН.
Автор фотосы.

7 марта с 8.00 до 18.00 ч. в РДК состоится
Ярмарка - распродажа пятигорские меха
короткие мутоновые шубы от 7000
длинные мутоновые шубы от 10000
жилетки мутоновые женские и мужские от 3000
АКЦИЯ
Меняем старые шубы на новые с доплатой, также оформляем кредит. В наличии имеются другие меха.
Только один день. Не пропустите.

“Күмәк көч”кә алдан язылу дәвам итә.
Хөрмәтле газета укучыларыбыз!

Иске Кулаткы районының почта бүлекчәләрендә 2017 елның икенче яртыеллыгына (июль-декабрь) газеталарга алдан язылу дәвам итә. Сез бүгеннән үк почта бүлекчәләренә, хат ташучыларга мөрәҗәгать итеп, «Күмәк көч” район газетасына иске бәяләр буенча, ягъни 349 сум 26 тиеннән, язылып куя аласыз, аннары хаклар күтәреләчәк.

ПӘНҖЕШӘМБЕ (02.03.)	ҖОМГА (03.03.)	ШИМБӘ (04.03.)	ЯКШӘМБЕ (05.03.)	ДҮШӘМБЕ (06.03.)	СИШӘМБЕ (07.03.)	ЧӘРШӘМБЕ (08.03.)
0 / - 4	+ 1 / + 3	+ 1 / - 4	+ 1 / - 5	0 / - 6	- 2 / - 8	- 2 / - 4

ЯҢАЛЫКЛАР



Россия Президенты Владимир Путин Алма-Атада узган XXVIII Бөтен дөнья кышкы универсиада да уңышлы чыгыш ясаган ил спортчыларына рәхмәт белдерде. Президент 23 февральдә имзалаган документтагы исемлектә күпчелекне алтын медаль яулаган Россия хоккейчылары, чаңгычылар, тимераякта узышучылар, сноубордчылар тәшкил итә.

● ● ●

Владимир Путин Россия Федерациясенең аерым канун актларының үз көчен югалтуы турында федераль законга кул куйган. Бу хакта "Российская газета" сы яза. Шушы үзгәрешләр белән Россия гражданнарына торакны хосусыйлаштыру вакыты чикләнми торган булды.

● ● ●

Россия Президенты В.В. Путин эшлекле сәфәре белән Казахстанда булды. 27 февральдә Алма-Атада ике ил Башлыгының официаль очрашуы үтте. Шулай ук Владимир Путин Киргизиядә һәм Таҗикстанда булды.

23 февраль көнне Губернатор С.И. Морозов беренче номерлы шәһәр клиник больницасының бала табу йортында булып, Ватанны саклаучылар көнендә бала туучы әниләрне шатлыклы вакыйгалары белән котлады һәм бүләкләр тапшырды. Бәйрәм көнендә өлкәдә 10 сәгатькә 10 бала туган. Шуларның 9сы – малай, берсе генә - кыз.

● ● ●

25 февральдә регион Башлыгы С.И. Морозов "Юнармия" Бөтенроссия хәрби-патриотик хәрәкәтенең вәкилләре белән очрашты. Очрашу дәвамында Губернатор әлеге хәрәкәтнең региональ бүлеген үстерү буенча инициативалар белән чыгыш ясады.

● ● ●

Ульяновск өлкәсендә меңгә якын кеше "Үлемсез батырлык" исемле II Бөтенроссия хәрби-тарихи фестивальдә катнашты. Әлеге чарадан регион Башлыгы С.И. Морозов та читтә калмады.

● ● ●

Сочида үткән инвестицион форумда регион Башлыгы С.И. Морозов «технологик долина»ны үстерү һәм ярдәм итү буенча тәкъдимнәре белән таныштырды.

Редакциягә язалар

Олы рәхмәтебезне кабул итегез

Февральнең унбишендә интернациональ бурычларын Әфган җирендә үтәгән ир-егетләребез белән очрашу матур традициягә әверелде. Әлеге күркәм чара безнең, сугышны үз күзләребез белән күргән, яралы күңелләр өчен бигрәк әһәмиятле, кадерле вакыйга.

Быелгы очрашуда барлык әфганчылар, район җитәкчеләре, әлеге бәйрәмгә битараф булмаучы райондашлар, мәктәп укучылары һәм укытучылары катнашты. Район Башлыгы Э.Ә. Ганеевның, район администрациясе Башлыгы И.А. Аблязовның, кеше потенциалын үстерү буенча район администрациясе Башлыгының беренче урынбасары В.А. Деникаеваның бу вакыйгага аеруча игътибар бирүе - безнең өчен зур куаныч һәм горурлык. Үзебезгә карата шундый игътибар, кайгыртучанлык, хөрмәт сизү – безне шатландырды һәм күңелләрне дәртләндерде.

Бу көнне безнең адреска җылы сүзләр, изге теләкләр, олы рәхмәтләр яңгырады. Район чарасын тиешле дәрәҗәдә оештыруда һәм үткәрүдә Иске Кулаткы район мәгариф бүлегенең мөдире Ф.З. Зайнетдиновага, Иске Кулаткы тарих һәм крайны өйрәнү музее директоры Р.М. Байбиковага, балаларга өстәмә белем бирү үзәге директоры Р.Н. Кузәевка һәм тулаем коллективына, мәдәният хезмәткәрләренә рәхмәт сүзләре җиткерәсе килә. Ә инде мавыктыргыч музыкаль чыгышлар ясаучы Иске Кулаткы беренче һәм икенче номерлы урта мәктәпләре укучылары шулай ук мактауга лаеклылар, алар безгә бәйрәм кәефе бүләк иттеләр.

Район Башлыгы Э.Ә. Ганеев һәм район администрациясе Башлыгы И.А. Аблязов тырышлыгы белән очрашу чәй табыны артында дәвам итте. Әфган җирендә интернациональ бурычларын үтәүче солдатлар бер-берсе белән аралашып, үткән вакыйгаларны искә алдылар. Без әлеге чарадан бик канәгать булдык.

"Хәрби туганлык" иҗтимагый оешма рәисе Шамил АРИФУЛЛИН.

Чаралар гөрләп үтте

Февраль аенда Иске Мостяк урта мәктәбендә бай чаралар атналыклары булып үтте.

"Химия атналыгы" н укытучы Алсу Шәүкәтовна Ханбикова, "Рус теле һәм әдәбияты" атналыгын укытучылар Н. Т. Фәйзуллина, С.Ә. Рәшитова, М. М. Нугаев, "Инглиз теле" атналыгын Р. М. Насыйрова мавыктыргыч итеп алып бардылар. Анда төрле викториналар, күргәзмәләр оештырылды һәм рефератлар каралды.

15 февральдә Бөек татар шагыйре Муса Җәлилнең туган көне уңаеннан укытучы Р. А. Нугаева чыгыш ясап, аның биографиясе турында сөйләде, ә инде укучылар шагыйрьнең шигырьләрен сәнгатьле итеп укыдылар.

Шул ук көнне Әфган сугышын, аның батырларын искә алу да булып үтте. Анда әти-әниләр дә катнаштылар, ә I-XI класс укучылары бу сугыш темасына әдәби монтаж күрсәттеләр. Аеруча Алсу Хабиеваның һәм Алсу Байгулованың чыгышлары күңелләргә хуш килде.

20 февраль көнне хәрби җырлар смотры булып узды. Анда төрле звенолар арасында X-VII-II сыйныфлар укучылары беренче урыннарга чыктылар. Шулай ук "Аҗаган" ("Зарница") уеннары да мавыктыргыч үтте.

21 февраль көнне мәктәптә "Ана теле" көне булып узды. Бу бәйрәмдә якташыбыз С. Сөнчәләйнең иҗаты искә алынды һәм татар халык уеннары оештырылды.

Әлеге чараларны үткәрүгә мәктәп директоры М. М. Нугаев һәм укытучы М. М. Нугаев зур көч куйдылар.

Зәкия ЗАЙНЕТДИНОВА.

2017 - Год добрых дел

Мы не одиноки

Здравствуйте! Я хочу выразить огромную благодарность сотрудникам реабилитационного центра «Парус Надежды», руководителю Зульфие Аксеновой, специалистам Фирузе Бимеевой, Динаре Сабитовой и Гузель Исмаиловой за их доброту, внимание, профессионализм и добросовестный труд. Эти специалисты всегда доброжелательны, с уважением относятся к каждому клиенту центра, с готовностью делятся своими знаниями. Фирузя и Гузял – настоящие рукодельницы, всегда готовы поделиться своми умениями и знаниями. У них можно научиться бисероплетению и сплести из бисера чудесные цветы и бусы, а из обычной бумаги можно сплести удивительные корзины, которые пригодятся и в быту и при проведении различных торжеств. Такими замечательными подарками можно порадовать и своих детей, и близких. Динара – обладает большим артистическим талантом и с удовольствием делится своими знаниями. Начиная с входа в центр нас всегда встречают с улыбкой и радостью, это очень приятно. Именно поэтому посетителям центра никакая депрессия не грозит, мы здесь и общаемся, и отдыхаем, и получаем огромное удовольствие от результатов своей работы. Пенсионерам здесь помогают справиться с одиночеством, с пользой провести свой досуг, именно так и появляется свое хобби. Занятия рукоделием хорошо успокаивают нервы и спасают от одиночества. Руководитель центра Зульфия Аксенова всегда рада всем посетителям. Она вместе с нами организовывает и проводит различные праздники, мастер – классы, увлекательные встречи и полезные беседы. Р. К. Бикмаев занимается нашим физическим воспитанием и приобщением к здоровому образу жизни. Он совершенно бесплатно проводит занятия по фитнесу. Здесь проявляются желания тренера помогать людям пожилого возраста. На его занятиях мы учимся быть здоровыми и активными, забываем о своих проблемах. Возмущает тот факт, что эти занятия проходят только по инициативе Р. К. Бикмаева и со стороны районной администрации никакой материальной поддержки не оказывается. Ведь здоровье – это основная ценность человеческой жизни. Если у нас в районе будет больше таких центров, объединений и инициативных людей, то и пенсионеры и люди пожилого возраста не будут чувствовать себя одинокими и больными.

Большое спасибо, за Ваш огромный труд, мы многому научились у Вас. Вы вдохновили нас, а самое главное мы поняли, что мы на верном пути.

Гульсум ГАВРИЛОВА. Старая Кулатка.

Уникальный шанс для молодых людей, проживающих в сельских территориях Ульяновской области от Российского Союза Молодёжи!

Хочешь кардинально изменить свою жизнь?

Хочешь стать успешным?

Хочешь получить бесплатно уникальную информацию и реальные инструменты повышения своего статуса?

С 6 по 11 марта 2017 года на базе детского оздоровительного лагеря «Юность» состоится лагерь-семинар Российского Союза Молодёжи на котором будут проведены тренинги и для молодых людей из сельской местности. (Для сравнения, многие предприниматели тратят от 20 тыс. руб.и выше, за прохождение бизнес-тренингов)

В целях формирования молодежного актива в сельских муниципальных образованиях региона запущен проект «Кадровый потенциал сельской молодежи «Устойчивое развитие!». Он реализуется Ульяновской областной общественной организацией Общероссийской общественной организации «Российский Союз Молодежи», Департаментом дополнительного образования, воспитания и молодежной политики региона при поддержке Общественной палаты Ульяновской области и Русского географического общества.

«Кадровый потенциал сельской молодежи «Устойчивое развитие!» получил статус федерального экспериментального проекта.

Принять участие в ее работе приглашаются активные и неравнодушные молодые люди в возрасте от 18 до 35 лет – по одному от каждого городского или сельского поселения региона.

Основной формой проведения кадровой школы станут тренинговые занятия.

Обучение активистов из числа сельской молодежи навыкам ведения успешной общественной деятельности и привлечения дополнительного финансирования на реализацию своих проектов – крайне актуальная на сегодняшний день задача. Как известно, чтобы участвовать в конкурсах субсидий и грантов, необходимо создать некоммерческую организацию, зарегистрировать ее в Министерстве юстиции РФ и открыть счет в банке. Мы решили пойти именно по этому пути и оказать отделениям «Российского Союза Молодежи» в муниципальных образованиях содействие в получении свидетельств о регистрации.

Накопив определенный опыт, районные отделения РСМ уже через год получат возможность принимать участие в федеральных, региональных и муниципальных конкурсах субсидий и грантов для социально ориентированных НКО. Их наиболее активные представители, в свою очередь, смогут представлять свои проекты на крупных молодежных форумах «iВолга», «Территория смыслов на Клязьме» и др. и претендовать на получение грантов для физических лиц в размере от 150 до 300 тысяч рублей.

Стать участником можно зарегистрировавшись на сайте https://regpart.ru/kpsm и стать участником группы ВКонтакте https://vk.com/ulprogrsm.

Телефон для справок: 8 (8422) 30-40-90.

Мин Герой урамында яшим

15 февраль көнне Кирюшкино авылы китапханәсендә Әфган җирендә батырларча һәлак булган якташыбыз Камил Хабушевның истәлегенә багышланган хәтер кичәсе үткәрелде. Әлеге чарада авылдашларыбыз, мәктәп укытучылары һәм балалар катнашты. Укучылар Герой-авылдашыбызның тормыш юлына багышлап шигырьләр укыдылар. Рамил Бикмәтов, Марат Шмаль, Николай Бесов "Мин Камил Хабушев урамында яшим" дип исемләнгән иншаларын да укып күрсәттеләр. Камилның бала һәм яшүсмер еллары турында искә алып сөйләдек. Соңыннан, бергәләп якташыбызның мемориаль тактасына чәчәкләр куйдык. Әфган сугышы һәм авылдашыбызның якты истәлеге безнең йөрәкләребездә мәңге яшәячәк.

Лилия АБДУЛЛИНА, китапханәче.

Внимание, «прямая линия»!

В целях защиты прав и законных интересов несовершеннолетних в Следственном управлении Следственного комитета Российской Федерации по Ульяновской области организована работа специальной линии «Ребёнок в опасности». Если вам стало известно о противоправных деяниях в отношении детей, сообщите об этом на короткий номер 123 или по телефону: (8422) 41-16-15 (звонок бесплатный). Также жители региона могут обратиться на телефон доверия Управления МВД России по Ульяновской области: (8422) 67-88-88.

БЕРГӘЛӘП УКЫЙБЫЗ

ÊÖÒÅÏ ÓÇÃÀÍ ÃÎÌÅÐ

Повесть

Зифа Кадырова

Акчарлаклар очкан Агыйделдә
Тугайларны ялгыз гизәсең.
Рушаниям, бәгърем,
Тугайларны ялгыз гизәсең,
Чәчкәләрне кемгә өзәсең?

- Кайттың да киттең, киттең. Асылгәрәй әчсә, һәрвакыт үзалдына Рушания белән сөйләште, бу аның инде каныына сеңгән. Ул гомер буе аның белән сөйләшә, ул ишетми, ишетмәсә дә аның белән сөйләшә. Менә әле дә ул Мәхмүт белән елга буеннан кайтты да туп-туры Рушания үскән иске йортның тәрәзә төбенә, нигезгә килеп утырды. - Киттең, ә мин менә китә алмыйм, синең шушы йортында сине уйлап, сине сагынып яшимен. Асылгәрәй хәйран гына исерек иде. Ул авыр сулап урыныннан торды, авыр адымнар белән күтәрмәдән күтәрелде, бик озак аяк киемен сала алмый маташты, өй ишеген тартты, өй эче җылы иде. - Инәй яккан, җылыткан. Эх, мескен, син дә көтәсең, ә ул төкермәде дә, китте дә барды. Асылгәрәй тәрәзә төбендә торган кечкенә сәкегә, өстәл кырына килеп утырды, өй эченә хәйран гына эчелгән коньяк исе таралды.

- Үзгәргәнсең, Рушания, әллә ни булган сиңа, элекке кебек күзләрең янып тормый. Әлдә урысыңны алып кайтмагансың, күралмыйм мин аны. Мин, гомумән, сиңа кагылган кешеләрне күралмыйм. Көнләшәмме? Әйе, үлеп көнләшәм. Ә нинди егет үстергәнсең. Миңа чыксаң, андый матур бала булмас иде шул, матурдан матур туа. Җирдә шундый матурлар гына яшәргә тиештер шул, кемгә кирәк минем кебек кәкре аяклы босманнар? Беркемгә дә кирәкми, хәтта мин үз-үземә дә кирәкмим. Ә Игорь шәп егет, мин хәтта бер минутка аны минем улым итеп хис иттем. Кызык, әллә нинди рәхәт хисләр кичердем. Эх, Рушания, никләр яратам мин сине шулай? Туганнан яратасың, ди инәй. Мин үзем дә шулай икәнен беләм. Күпме диңгезләр гиздем, нинди генә илләрдә булмадым, нинди генә чибәрләр күрмәдем, тик сине оныттырырдайларны очратмадым. Син ниндидер урыска балалар таптың, яраттың, үзеңне яраттырдың. Нинди бәхетле кеше ул, ә мин бер генә үрелдем, миннән котың алынды. Мин хыялымда күпме тапкырлар синең толымнарыңны сүтеп үрдем, чак кына иреннәреңә кагылдым, күзләреңнән үптем, тик болар барысы да хыялда гына калды. Син кичә кулымны кулыңа алгач, йөрәгем туктый дип торам. Синең кулларың салкынча иде. Ә унычы класста укыганда, ярдәм ит дип керә идең, минем сине шундый кысып-кысып кочаклыйсым, суырып-суырып үбәсем килә иде. Мин көчкә тыелып утыра торган идем, син һаман миңа кайнар кулларың белән кагыла идең дә башымны әйләндерә иде. Берни уйлый алмыйм, башта бер генә уй - Ходаем, ташланып хур булмыйм. Ә син хәлемне аңламыйсың, каршыма килеп иеләсең. Синең күкрәкләреңнең һәр ел саен күпмегә үскәнен чамаларга тырыша идем. Асылгәрәй үзалдына көлеп куйды. - Эх, Рушания, син фишка сорыйсың, ә мин каршымда гына торган күкрәкләр турында уйлыйм. Ә кичке уеннар? Син күрмәдең минем ни көткәнне, анда караңгы, мин сиңа соклана идем, синдә генә иде иң төз, иң матур аяклар. Егетләргә әйтеп куйдым: ялгыш кына тимәгез, ботарлармын, дидем. Былтыр классташлар очрашуы булды, сине тапмадылар. Мин белдем, белсәм дә әйтмәдем. Мин һәрвакыт синең кайдалыгыңны белеп йөрдем, син яхшы яшәдең, начар булса, мин сине... Хәмит миңа бик зур үпкәсен белдерде. «Эх, дус дигән була, ни үзеңә, ни кешегә. Мин шундый гашыйк идем, хәзер дә оныта алмыйм, инде бабай булдым, ә Рушаниянең чибәрлеге һаман йөрәк түрендә яши. Шулай ук сиңа үпкәм зур, классташыңа озатырга бирмәдең, әллә нинди урыска биреп җибәрдең»,- ди. Кем аңласын минем хәлемне? Алар өйләнгәннәр, балалар үстереп әби-бабай булганнар, ә мин зимагур кебек читтә йөрдем дә йөрдем. Юк, Рушания, йөрәктә синең урынны алырдай кеше табылмады, ә мин эзләмәдем дә.

- Ә син эзлә, Асылгәрәй, яратма мине, яратма.

- Ничек яратмыйм, син минем сөягемә ябышып үскән тире кебек. Мин бәләкәй чакта уяну белән сезнең тәрәзәгә карап ката идем, син килеп кул болгагач кына минем өчен кояш чыгып, яңа көн туа иде. Озак та йоклый идең син. Мин тын белән өреп эреткән пыяланы әни күреп, юкара пыяла, озакламый тишелер, ахрысы, дип көлә иде. Ә берсендә мин ул туңган ике катлы пыяланы кисәү агачы белән сугып ваттым, чөнки беренче катын чистарттым, ә тышкы каты эреми дә эреми. Мескен инәм минем белән ни генә күрмәде. Сиңа әни кертми башлады, сине дә кертмиләр безгә, мин сабырлыгым бетеп елыйм, талашам, сине күрәсем килә. Миңа кушылып инәй дә елый, аның да сине бик тә күрәсе килгәндер. Хәзер күп нәрсәләрне аңлыйм, инәй ничек түзгән безнең белән?

Рушания акрын гына урынныннан торды да аның каршысына килеп утырды. Урамда сызылып кына таң ата, өйгә зәңгәр су төс керә. Асылгәрәй каршысына килеп утырган шәүләгә карап торды.

- Менә шулай күземә дә күренә башладыңмы инде. Кешеләр белмиләр әле бу йортта җүләрләрнең икәү икәнен, Мәхмүт кенә дип уйлыйлар. Ул көннең буе үзалдына сөйләнә, мин төннең буена.

Рушания акрын гына Асылгәрәйнең кулына кулын салды.

- Асылгәрәй, - диде чак ишетелерлек тавыш белән.

Асылгәрәй кинәт айнып киткәндәй булды, сикереп торды да ишеккә юнәлде. Ишек ябылганда, «уйлана торгач, килеп җиттем бугай», дигән сүзләр ишетелеп калды. Рушания ни булганын аңларга да өлгермәде. Өйдә ут юк, өзгәннәр бугай. Асылгәрәй килеп кергәндә ул юрганга төренеп, җылынып кына йокыга китеп бара иде, эндәшергә дә куркып ятты. Кем уйлаган аның шулай йөрәген ачар дип. Хәзер ни дип чыгып чапты инде? Ярый, иртән күз күрер.

Иртән Рушания өшеп уянды, тәрәзәгә кояш нурлары кергән, ул бераз селкенми дә ятты, кичә ишеткәннәрне кабат күңеленнән үткәрде. Ник дорфаланып чыгып китте инде? Эх, Асылгәрәй, нишли алам соң мин синең өчен? Мин хәзер үзем дә бәхетсез. Рушания торып киенде, өй суынган. Инәй яныына керергә кирәк, Асылгәрәй әйткәндер инде минем монда икәнне. Рушания зур өйгә кергәндә, алар өчәүләшеп чәй эчеп утыралар иде.

Хәерле иртә, миңа да чәй эчерәсезме? Өшедем, өй суынып киткән, - диде. Бөтенесе аңа текәлеп каттылар. Беренче булып Фатыйма инәй телгә килде:

- Рушания, син кайдан, ә улың кая?

- Мин уйладым-уйладым да кире борылдык. Игорь кайтып китте. Сезне уятып торасы килмәде, мич яктым да ятып йокладым.

Күз кырые белән генә Асылгәрәйгә карап алды, ул күтәргән чәйле кәсәсен куярга онытып, Рушаниягә текәлгәде. Рушания шунда гына аңлады, Асылгәрәй аны чынга апмаган, күземә генә күренә дип уйлаган, ахрысы. Аның кычкырып көләсе килде. Асылгәрәй кәсәсен куйды да, өйдән чыгып китте. Аның каравы... Мәхмүт сөенде, аны кочаклап алды, йөгертеп кәсә китереп куйды.

-Рушания апа кайткан, - дип сөенде. Фатыйма инәй Асылгәрәй артыннан ябылган ишеккә карады, аннан баш селкеп куйды.

- Эх, бала, атаң баласы. Рушания, кире килеп яхшы иткәнсең, бик күңелем кителеп калган иде шулай кинәт китүеңә. Мин, беләсеңме, сине Маһинурларга алып барам, ул берсе көнгә аш уздыра. Фатыйма килеп кызын иңнәреннән кочып алды. - Аңлашыйк, балам, җир астыннан юллар юк, исән чакта аңлашып калыйк.

Рушания агарып китте. Ул үзе дә Любаның анасына шулай диде түгелме соң? Кичермәс гөнаһлар булмас.

- Дөрес әйтәсең, әни, аңлашырбыз.

- Рәхмәт, балам, мине аңлавыңа. Фатыйма кызының иңнәреннән сөйде, күз төпләрен яулык очы белән генә сөртеп алды. - Яшә, балам, азрак безнең белән. Менә ямьле язлар, җәйләр җитә, мин сине торналар утравына алып барырмын, жиләккә барырбыз. Нигә, балам, бу яулыгыңны бер дә салмыйсың, әллә толымнарыңны кистеңме?

- Кискән идем шул, килешми икән, шуңа яулык белән йөргәнең яхшырак.

- Ярый, балам, сиңа болай да бик яхшы, яулыгың да килешеп тора, бик килештереп бәйләгәнсең, булсын. Ярый, мин өй эшләрен карыйм, син ял ит. Ул тагын Рушаниянең аркасыннан яратып-сөеп куйды. - Әйдә, Мәхмүт балам, тавык суеп, мунча ягып җибәрик.

Асылгәрәй әллә ике көн күренмәде, әллә качып йөрде. Иртәнге якта Фатыйма инәйнең нәрсәгәдер тиргәшкәне ишетелде.

- Кеше төсле сөйләшергә өйрәнәсеңме, юкмы син? Әй Аллам, анда бикләнеп ач утырып, кемне нәрсәгә ышандырмакчы буласың, чык дим аннан. Хәзер алайса Мәхмүт ашарга алып төшәр, ишегеңне ач. Рушания Фатыйма инәйгә карап куйды. - Менә шундый телсез нәрсә.

- Кая, мин алып төшим, миңа аның белән сөйләшергә кирәк.

- Сөйләш, балам, әй интектереп тә куя үзен, мин бит аны үтәдән күрәм.

Рушания подвал ишеген килеп шакыды, ишек ачык иде, эчтә караңгы, Рушания капшаныып табып, утны яндырды.

- Сүндер, Рушания апаң кайда?

- Мин монда, - диде Рушания акрын гына.

Асылгәрәй әллә нишләп китте, кинәт артына борылып карады, кырынмаган һәм бик йончыган иде ул. Рушания аңа терәлә язып килеп басты.

- Әнине борчымыйк, Асылгәрәй, баласы ач утырганда нинди инәйнең тамагына аш үтсен ди. Мин кайттым, ә синең сөйләшәсең дә килми.

- Мин болай да артыгыннан күп сөйләдем сиңа.

- Мин аны елый-елый тыңладым, мин дә сөйләр идем дә, син никтер чыгып качтың. Асылгәрәй эндәшмәде. Ул карашларын яшерде. - Ни булды сиңа, ник качасың? Әйтәсе сүзләр әйтелгән. Мин сине бик тә бәхетле итәргә теләр идем дә бит, нәрсә дә булса үзгәртергә соң шул инде. Рушания аның яңакларыннан сыйпады, күзләренә текәлеп карады. - Мин синең бәхетсезлегең, Асылгәрәй, мин моны хәзер генә аңладым. Мин дә бәхетсездер бәлки, син миңа кирәк, синең ярдәмең кирәк, ишетәсеңме? Рушаниянең күзләрендә яшь. Асылгәрәй ни үле, ни тере бер урында каткан килеш тик тора. - Мин дә ялгыз, ирем яшь хатынга чыгып китте, минем сөйләшер кешем дә юк, кемгә сөйлисең инде андый хәлләрне. Асылгәрәй, башына кайгы төшкәч кенә исенә төшкән диярсең, син хаклы. Рушания яшьле күзләрен Асылгәрәйдән яшермәде. - Минем сездән башка мине аңлардай кешеләр юклыгын аңладым.

Рушания Асылгәрәйнең муеныннан кочып, иңенә башын салды. Асылгәрәйнең йөрәге бер туктады, бер сикерде. Калтыранган куллары белән нишләргә белмәде, җитмәсә, ике көн юынмаган-кырынмаган, ул тагын коелып төште. Рушания кулларын аның муеныннан алды, кабат яңагыннан сыйпады да, подвалдан чыгып китте. Асылгәрәй көчкә почмакта торган урындыкка килеп утырды. Тирә-якта һәм аның өстендә сизелер-сизелмәс кыйммәтле хушбуй исе калды.

- Эх, инәй хаклы, телсез хайван мин, ни кочаклый алмадым, ни бер җылы сүз әйтә алмадым.

Асылгәрәй ике арада килеп туган ачык сөйләшүдән бермәлгә югалып калды. Менә ничек икән бит хәлләр. Бу сөйләшү аны сөендермәде, белсәң иде, ул урыс тәресе кемгә алыштырды икән аның Рушаниясен? Асылгәрәй кабат - кабат Рушаниянең яшьле күзләрен исенә төшерде, йөрәгә кысып-кысып алды. Бер нәрсә көн кебек ачык - ул аны элеккечә ярата. Бервакыт түзми өзгәли-өзгәли яратыр да я үлер акылдан язып. Нинди сихри көчләреңә бар синең? Мин дә бит иллегә җитеп киләм, яныып бетәргә була, ә син һаман мине акылдан шаштырасың. Бөтен яшьлегем, ирлегем сарыф ителми сине көтте, сине теләде. Асылгәрәй башын учларына кысып утырды.

- Я Ходай, юлбарыстан көчеккә әйләнәм- төшке ашка кергәндә ул инде кырынган, юынган, киемнәрен алыштырган. Ул керү белән Рушаниягә карап алды, ә ул берни булмагандай аз гына елмайды. Шул чакта аның йөрәгә кабат тыпырчынып куйды. Мәхмүт сәенә-сөенә кайтып керде. Өч литрлы банка белән болганчык су күтәргән, ул аны әнисе алдына китереп куйды.

- Әни, каен суы, Рушания апага эчерик.

- Эчерик, улым, эчерик. Мин дә яшь чагында каен суы җыеп, Айбикә инәйгә алып кайта идем, ул иң башта кызым матур булсын, күз тимәсен, дип синең битеңне юа, аннан үзеңә эчерә иде. Беренче тамчыларын күзләреңә сөрт, күзләреңнең нуры бетмәсен. Эч, балам эч, тәнең сихәт алсын. Җир-ана үзе күкрәк сөтен бирә.

- Рәхмәт, Мәхмүт. Асылгәрәй, безнең каенны хәтерлисеңме, зөмбердәтеп су бирә торган иде, исәнме икән, корыгандыр шул инде?

- Яшен сукты шул аны, балалар, суы тәмле иде шул. Кайчандыр якын гына иде дә, аннан авыл зурайды, төбен кисеп, урынына йорт салдылар.

Рушания кайтканны ишетеп, яше-карты хәл белергә керде. Маһинурларга кунакка бардылар, дөньяларының шәплегенә искитмәле иде. Бәләкәй генә буйлы Әхтәм абыйсы һаман җор сүзле, шаян; ак башлы картка әйләнгән, балалар, оныклар бер көтү. Таза-таза гәүдәле баһадир уллар үстергәннәр. Барысы шатланышып каршы алдылар. Маһинур апай тазарган, элек Әхтәмнән ике башка озын булса, бүген бер башка гына озын. Балалары тирә-ягында ата-аналары өчен өзгәләнеп торалар. Рушания үзенең тирә-ягында ниндидер шатлык тоеп утырды. Ул соңгы елның һәр көнен куркып, кайгырып - боегып үткәрде, ә бүген аңа никтер җиңел һәм рәхәт. Берни дә уйламый, кешеләр сөйләшә-көлә, тирә-ягында тормыш кайнап тора. Алар кичкә чаклы рәхәтләнеп утырдылар. Рушания хәтта даруларын да ашарга онытты. Кайтырга чыкканда кич шундый матур иде, алар ашыкмыйча гына Фатыйма инәсе белән урам буйлап атладылар. Үткән берәү, исәнмесез, Фатыйма абыстай, дип үтәләр. Бер Рушаниягә, бер Фатыйма абыстайга карыйлар, алар бик тә охшашканнар иде шул. Рушания үзе дә сизмәстән шушындагы тормышка күнегеп китте. Улы хаклы, шулчаклы туганнарың була торып, ник ялгыз яшәргә? Кичтән Игорь шалтыратты: «Әни, хәлең ничек, берәр нәрсә кирәкмиме?» «Юк, улым, миңа шундый рәхәт монда, элегрәк кайтмавыма үкенәм». Рушания үз өендә генә яшәргә булды.

- Инәй, син үпкәли күрмә, бу Асылгәрәй өе, ә тегә минем өй. Мин үз өемдә яшим.

Асылгәрәй моны белгәч, тешен кысып кына:

- Минем өйнең нәрсәсе ошамады? - диде.

- Ошый, барысы да ошый, мин безнең балачакны сагынам. Син тәрәзә төбендә көтеп торырсың, мин иртән торып кул болгармын.

- Синең торганыңны көтсәң.

Рушания бозларыңны эретерлек итеп елмайды.

- Асылгәрәй, мин сиңа карыйм да, яшемне онытам, әле һаман балачакта кебек, бернинди кайгым юк, миңа шундый рәхәт.

Асылгәрәй берсүзсез генә басып торды:

-Ни кирәк, телевизор кирәкме?

- Юк, берни дә кирәкми, ут булса, шул җиткән.

Тик шулай да иртән өстәлдә матур самавыр, кәсәләр барлыкка килде. Кичен өч литрлы банка белән умарта балы күтәреп килеп керде. Рушания аны торып каршы алды.

- Алайса, әйдә, бергәләп чәй эчәбез.

- Башка вакыт, - диде дә, чыгып китте.

Рушания үпкәләмәде, үзалдына елмаеп кына куйды. Кичен Инзир буенда гармун тавышы тагын моңайды. Рушаниянең дә бик тә барасы килсә дә, ул аны бакчадан гына тыңлады. Яз, һавада әллә нинди дулкыннар йөзә, йөрәкләрне җилкендерә. Төнге урамга шомырт исе таралган. Рушания йокларга яткач та, уйланып ята. Үткән тормышына, үткән гомеренә йомгак ясарга, үткән авыр елны уйламаска тырыша. Аның ул тормышы анда калды. Туган якның үз тылсымы бар диләр, бәлки хактыр, кайтканнан бирле бернинди авыртыну сизми. Бәлки ул бүтән беркайчан да авыртынмас? Иртәгә Ильич белән сөйләшергә кирәк, югалткандыр, ул бит аңа ике генә көнгә китәм, дигән иде. Рушания татлы йокыга талды, ул монда кайтканнан бирле бик тыныч йоклый, чөнки җанын берни дә борчымый. Иртән Рушания уянганда кояш күтәрелеп киләә иде, ул бераз иркәләнеп ятты, аннан кичә биргән сүзе исенә төште. Тәрәзә төбенә килеп утырды, каршы тәрәзәгә карады. Каршы тәрәзәдә кеше күренмәде, аның бакчага күзе төште, Асылгәрәй алмагачлар төбен казып йөри иде. Рушания торып чәй куйды да, тышка чыкты.

- Озак йоклыйсың.

- Мин синең кул болгаганыңны көтеп утырдым.

Асылгәрәй эшеннән туктап бераз аңа карап торды.

- Асылгәрәй, мин дә менә бу өй тирәли гөлләр утыртыр идем, орлыклар кайдан алырга була икән?

- Алып кайтырмын, утыртырсың.

- Балалар, чәй эчәргә керегез. Асылгәрәй, йоклый киләсеңме син, юкмы? Коймак пешердем, әйдәгез.

Рушания берсүзсез Фатыйма инәсе артыннан иярде. Өйгә кергәч, ул ипләп кенә сорап куйды:

-Инәй, Асылгәрәйнең гаиләсе бармы?

- Аның гаиләсе син дә мин, өйләнмәде, һәрхәлдә, ялгыз кайтты. Үзе юкта мин сиңа аның бүлмәсен күрсәтермен әле, анда ни генә юк. Өйләнмәве дә аңлашыла, сине генә яратты, туганнан ул сине ярата. Сине беренче күрү белән үзенә йолкып тартты да, әй үбә, әй үбә, нишләтергә белми ябыша. Үз аягы белән йөри башлагач, җәй дими, кыш дими, ялан аяк, ыштансыз килеш сине эзләп торып чаба иде. Айбикә инәй кычкыра: «Фатыйма, ал бу җен баласын, тәтәйләрен шалтыратып кереп килә, шомыртымны оялтып». Барый абзый эче катып көлә иде Айбикә инәйнең шулай дип чәбәләнүенә. Ул гомумән ыштансыз ир балага карый алмый иде, үзе ояла иде бугай. Эх, балам, бар иде авыр да, рәхәт тә заманалар. Сез бәләкәй чакта рәхәт булган икән. Син бер дә үз гаиләң турында сөйләмисең.

- Берәр вакыт сөйләрмен, инәй, бер дә исемә төшерәсем килми. Миңа монда сезнең белән рәхәт.

Алар бер гаилә булып җыелышып ашадылар, сөйләштеләр, көлештеләр. Акрын гына көннәр бер җайга салынып китте. Бер төнне йоклап ятканда өй ишеге ачылды да, ашыкмый гына тәрәзә төбенә Асылгәрәй кереп утырды.

- Йоклыйсыңмы?

- Ятам шунда уйланып.

- Мин туйдым уйланып, күпме генә уйлансаң да, бу тормыш барыбер без дигәнчә булмый.

Караңгы өй эчендә икесе ике башта сөйләштеләр, ничек тә ачылып сөйләшеп китә алмадылар.

- Мин иртәгә Уфага китәм бер өч көнгә, кирәкле әйберен юкмы, шуны сорарга кергән идем.

Тагын тынлык урнашты.

- Ник алай озакка, Асылгәрәй?

- Өч көн озакмыни?

- Белмим, миңа калса, синсез күңелсез булыр.

- Өч көн - утыз ел түгел, Рушания.

Асылгәрәй чыгып китте. Ни әйтергә теләде моның белән? Асылгәрәй күздән югалгач, чынлап та, йорт буш, күңелсез булып калды. Фатыйма инәй: «Әйдә, мин сиңа аның байлыгын күрсәтәм»,- диде. Асылгәрәй бүлмәсе бикле түгел, тик ачкыч тишегендә тора. Чынлап та, бу зәңгәрсу бүлмәдә ни генә юк, әллә нинди диңгез астыннан чыккан ташлар, йолдызлар, зур-зур кабырчыклар, аларның матурлыклары искитмәле. Стенада әллә нинди матур-матур картиналар. Рушания ныклабрак карады - ул картиналарның почмагы саен аның сурәтләре ясалган, кайда карама - Рушания. Ул күлдан нинди генә формада ясалмаган! Рушания күктә, ә ул аста, кулларын өскә сузган. Ул корабльдә, ә Рушания күктә ай сүрәтендә. Фатыйма инәй шкафны ачты, анда ап - ак һәм кап-кара диңгезче костюмнары эленеп тора, медальләре дә бар. Ул горурланып сыйпап куйды.

Дәвамы бар.

ИХТИРАМГА ЛАЕК ШӘХЕСЛӘР

Хезмәттә үткән гомер

Бу дөньяда иң кыйммәтле нәрсә - кеше гомере. Әле яңа гына мин яшим дип дөньяга аваз саласың, кай арада инде аккан судай гомер үзенең олылыгын дистәләгән еллар белән билгели. Яшәү дәверендә борчулары, шатлыклары бергә үрелеп барганда, чәчләргә чал куныып өлгерә, йөзеңне җыерчыклар күмә.Ә еллар узган саен адәм баласы үзенең туган көннәрен сабыррак каршы ала башлый. Артка борылып караган саен узган гомер юллары, истәлекләре күз алдына килә. Узган еллар, үтелгән юллар заяга узмаганлыгы, гомер көзләренә кергәндә җимешләр инде өлгергәнме – менә шуларны әкрен генә барлый башлый.

Шушы көннәрдә Иске Кулаткы эшчеләр бистәсендә гомер итүче, “Районның Мактаулы гражданины» исемен йөртүче Расим Ахатович Абәйдуллин истәлекле туган көнен – 85 яшьлек юбилеен каршылады. Ул - балаларына сөекле әти, оныкларына һәм оныкчаларына яраткан бабакай, туганнарына – киңәшче, ярдәм кулы сузучы, бик күп санлы дусларына – тугры дус. Гомер буе туган җирендә хезмәт куеп, уңган, тырыш, бик сабыр, ярдәмчел булуы белән халык арасында зур ихтирамга лаек була. Аны районда белмәгән кеше юктыр, мөгаен.

Юбилярыбыз 1932 елның 27 февралендә Вәсвиҗамал апа һәм Ахат абыйның ишле гаиләсендә өлкән бала булып дөньяга туа. Аның тормыш юлының иң татлы, иң куанычлы еллары авыр сугыш чорына туры килә.1942 елда әтисе Ахат абый фронтка алына һәм сугыш кырында хәбәрсез югала. Вәсвиҗамал апа дүрт баласын кочып, татар хатын-кызларына булган сабырлык белән әлеге әйтеп бетергесез югалтуны кичерә.

Гаиләдә иң өлкән бала булганга, Расим абый мәктәптә башлангыч сыйныфларда белем алып, җиң сызганып эшкә керешә. Яшьтәшләре белән бергә урак урган, көлтә бәйләгән, ат җигеп саламын, печәнен ташыган, бер эштән дә баш тартмый. Озакламый әниләре сәламәтлеге какшау сәбәпле, вафат була. Моның никадәр авыр икәнен үз башына төшкән кеше генә аңлый ала.Ике сеңеле һәм энесе Расим абый карамагында тәрбияләнәләр. Балачактан ук ятимлекнең бар ачысын татырга туры килә аларга. Әти-әнисез килеш, әллә ни иркәләнеп ятарга туры килми сабый балаларга.

Туган җиргә мәхәббәт, җир хезмәтен яратуы үзенекен итә: Расим абый чит җирләргә китеп, бәхет эзләми- гомерен авыл тормышы белән бәйли. Хезмәт биографиясен тракторчының ярдәмчесе буларак башлап җибәрә. Тракторчыга таныклык алып, озакламый үзе дә тракторга утыра. Үз җиренә хезмәт итәргә яратканга күрә, техника сөйгәнгә әлеге тынгысыз эшне үз итә. Ул һәрвакыт хезмәттә була.

Иске Кулаткыга юллама белән җибәрелгән Кылмаюр кызы, һөнәре буенча агроном - яшь, чибәр Рузалия Ахметсагировна белән гаилә корып җибәрәләр. Рузалия апа да гомере буе авыл хуҗалыгында намуслы хезмәт куя. Районда авыл хуҗалыгын күтәрүгә армый-талмый хезмәт итеп, үзеннән зур өлеш кертә.

Тырыш, сәләтле Расим абыйны җитәкчеләр Карсундагы механизация училищесына укырга җибәрәләр. Биредә 6 ай дәвамында ул яңа - комбайнчы һөнәрен үзләштерә. Һәм 15 ел дәвамында комбайн штурвалы артында була. Көнне-төнгә ялгап, урып-җыю эшләрендә югары хезмәт күрсәткечләренә ирешә, үзенә тапшырылган техникадан максималь файдаланып, эшен сыйфатлы үти. Ел саен алдынгылар сафында була.

Җаваплы, тынгы белмәүче хезмәткәрне Иске Кулаткы совхозына бригадир итеп билгелиләр. Әлеге эшен дә ул зур җаваплылык белән башкара, коллектив белән бер сүздә, бердәм, тату булып, нәтиҗәле эш күрсәтә. Биш ел дәвамында мастерской белән җитәкли.

Расим Ахатович нинди эшкә алынса да, йөкләнгән вазифаларын җиренә җиткереп башкара. Аның кулыннан килмәгән эше юктыр, мөгаен, ул “алтын куллы” механик буларак та үзен таныта. Шуңа күрә лаеклы ялга кадәр фермалар буенча механик эшен башкара.

Сабыр, күркәм холыклы, эш сөючән, ярдәмчел булганга, аңа бөтен эш җиңел бирелә. Ул кайчан да уңыш артыннан чапмый, бары тик хезмәтен ярата. Китап киштәсендәге күп санлы Мактау кәгазьләре, Почет грамоталары, медальләр аның тынгысыз хезмәтенең, ялсыз, бәйрәмсез көнне төнгә ялгап, тир түгеп эшләвенең бәяләп бетергесез җимешедер.

Расим Ахатович һәм Рузалия Ахметсагировна гаилә учагын саклап, 60 ел бергә дус-тату гомер итеп, кызлары Гөлфияне, Наиләне, Фәридәне һәм уллары Фәритне үстерделәр. Бар көчләрен балаларны сәламәт, белемле, тәрбияле итү өчен куйган әти-әниләрнең максаты да тормышка аша. Әлеге гаиләдән чыккан балалар бүгенге көнгә үрнәк тормыш алып баралар.

- Әти-әни башкаларга соклануырлык итеп яшәделәр, безгә җил-яңгыр тидерми үстерделәр, безнең өчен күп көч түктеләр. Авырлыкларны зур сабырлык белән җиңәргә, сынмаска -сыгылмаска, кешеләргә карата мәрхәмәтле булырга өйрәттеләр. Кызганычка каршы, хәзер инде әниебез арабызда юк инде. Әтиебез генә исән булсын. Аның янәшәбездә булуы - безгә зур куаныч. Ул гомер буе безгә үрнәк булды. Эштә өлгерлеге, уңганлыгы белән аерылып торган газиз әтиебезгә, әлбәттә, бу олы яшьне бирәсе килми. Ул бүген дә безнең өчен олы терәгебез. Без аның алдында баш иябез һәм олы рәхмәтләребезне җиткерәбез!, - ди кызлары.

- Тормыш иптәшемнең бакыйлыкка күчүенә дә инде быел 2 ел тулды. Әмма мин ялгыз түгел. Бүген мин 4 балам, 5 оныгым һәм 4 оныкчам белән бәхетле. Өем бервакытта да буш торганы юк. Кызларым көн дә яныма киләләр, тәмле ашлар белән сыйлыйлар. Аларның кайгыртуларын, игътибарын тоеп яшәү – миңа көч бирә. Күршеләрем дә бик яхшы, дус-тату гомер кичерәбез, - ди Расим Ахатович.

Әйе, 85 яшь - бик озын гомер кебек тоелса да, көндәлек эш-мәшәкатьләр белән бер мизгелдәй сизелми генә үтеп тә киткән. Иң мөһиме ул бушка узмаган. Яшәү мәгънәсе балалар һәм оныклар тормышында да ачык чагылыш тапкан. Һәр туар таңга сөенеп, күңел күтәренкелеген төшермичә бала-оныкларына терәк һәм кирәк булып, тагын да юбилейларны каршыларга язсын әле Расим Ахатовичка.

Гомер бәйрәме уңаеннан без дә олы юбилярга нык сәламәлек, күңел тынычлыгы, шатлыклы көннәр, бала-оныкларының күңел җылысын тоеп, игелекләрен күреп, озын гомер кичерүен телибез.

Гөлназ КУЗӘЕВА.

Тирән эзләр калдырып

Иске Атлаш авылында гомер кичерүче Алимҗан Исхакович Юртаев 1 мартта үзенең 85 яшьлек олы юбилеен каршы ала. Гомер агышында аңа яшәүнең төрле ягын татырга туры килгән. Сугыш елы баласы буларак бу чор аның йөрәгендә тирән эзләр калдырган, ул әлеге вакытны бүген дә хәтереннән чыгармый. “Күмәк көч” район газетасының журналистлары белән булган очрашуда да сүзне язма героебыз шушы хатирәләрдән башлап җибәрде:

- Мин 1941елда мәктәптә укыганда, әтиемне Бөек Ватан сугышына чакырдылар, – дип искә ала Алимҗан Исхакович авыр балачагын. - Миңа ул вакытта - 9, сеңелләрем Рокыяга -7, Сәкинәгә 5 яшь иде. Аларны тәрбияләп үстерер өчен, барлык авырлыкны әниемә, үземә татырга туры килде. Без аның белән сбруй (дирбия) табыштырып сыерыбызны җигәргә өйрәттек һәм мәктәпкә утын, кырда кунучы механизаторларга аш-су ташыдык.

Сугыш тәмамланганнан соң, 1946 елда колхозда туңга сөрү буенча җыелма бригадалар оештырыла һәм яшь малай төнге сменада плугарь булып эшли.

1948 елда “Прожектор” колхозы аны өч айлык хисаплаучылар мәктәбенә укырга җибәрә, белем алгач, хуҗалыкта хисапчы булып хезмәт итә.

Аннан соң яше тулган егет Совет Армиясе сафларында өч ел буе Ватан каршында изге бурычын намус белән үти һәм часть командованиесе исеменнән Рәхмәт хатлары алып туган ягына кайта.

1955 елда “За мир” колхозы идарәсе Алимҗан Исхаковичны колхоз рәисенең урынбасары итеп билгели һәм шул ук елда аны комсомол оешмасының секретаре итеп сайлыйлар. Ул бу вазифаны өч ел дәвамында башкарып, үзен гел уңай яктан күрсәтә.

Коллективта эшне оештыру сәләтләрен исәпкә алып, 1958 елда Иске Кулаткы КПСС райкомы Алимҗан Исхаковичны Ульяновск шәһәренең совет партия мәктәбенә укырга җибәрә. Аны тәмамлагач, Иске Атлаш авылы Советы рәисе булып эшли.

Бу урында хезмәт иткәндә ул читтән торып КПСС Үзәк Комитетының югары партия мәктәбен тәмамлый, шуннан соң аны 1962 елда хуҗалыкның партоешма комитеты секретаре итеп сайлыйлар.

Бай тәҗрибә туплаган җитәкче бу вазифаны 23 ел дәвамында карусыз башкара, 1992 елга кадәр “За мир” колхозының профсоюз комитеты рәисе булып эшли. Ул елларда хезмәт уңышлары турында Совет хөкүмәте тарафыннан тапшырылган “Данлы хезмәт өчен” дигән медальләре, башка бүләкләре дәлиллиләр.

- Элек заман без тату гаиләдәй бердәм, дус булып яшәдек, эшләребездән канәгатьлелек алып, зур уңышларга ирешә идек, - дип сүзен дәвам итә Алимҗан Исхакович.

- Нинди генә авырлыклар булса да, зур коллектив белән киңәшләшеп, аларны җиңеп килдек. Шушы уңайдан 1981 елда, корылык елында, терлек азыклары, салам әзерләргә дип Украинага баруыбыз бүген дә истән чыкмый. Мин бу ерак командировкада 33 кешелек бригада белән җитәкчелек иттем һәм анда кырык көн булдык. Шушы кырык көннең бер көне бүген дә хәтеремнән чыкмый. 26 август көнне газиз әниемнең үлүе турында минем исемгә телеграмма җибәрелә, ләкин без юлга чыгып киткәнгә күрә, ул хәбәр минем кулыма эләкми.Ике көннән соң без Кузнецк шәһәренә килеп төштек, каршы алырга килгән шофердан әниемнең үлүе, аның күмелүе турында ишеткәч, үз-үземне кайда куярга белмичә хушымнан яздым.

Кеше нинди генә кайгы – хәсрәт күрсә дә, аңа күнегә, түзә икән.

Алимҗан Исхаковичның намуслы хезмәте эзсез үтми: 2003 елда Иске Кулаткы район Советы депутатларының карары белән аның исеме районның Алтын Китабына кертелә.

Халыкка, җәмгыятькә файдалы эшләр башкарып, сизелми дә еллар үткән. Юбилей алдыннан Алимҗан Исхакович һәммәсендә күз алдына китереп, истәлекләр хатирәсендә яныып яши. Ул үзенең тормыш иптәше Мәүҗүдә Исхаковна белән бик тату яшәде. Алар бергә ике бала үстерделәр. Уллары Нияз Казан университетын тәмамлап, Ульяновск “Авиастар” заводында хезмәт итә. Кызы Руфия Ульяновск педагогия университетын тәмамлап, Павловка районында укытучы, мәктәп директоры булып эшләде.

Алимҗан Исхаковичның 4 оныгы һәм 3 оныкчасы бар. Ул аларга шатланып туя алмый. Олы юбилей алдыннан балалары да, оныклары да бер табын артына утырып: "Юбилеең котлы булсын, безнең кадерлебез! Исәнлектә -саулыкта тыныч яшә!",- дип изге теләкләрен юлларлар.

Рөстәм АРИФУЛЛИН.

ТӘБРИКЛӘҮЛӘР КАБУЛ ИТЕГЕЗ!

Яңа Яндука авылында гомер кичерүче Зәкәрья Сәитович ӘБДРӘШИТОВ 28 февральдә 80 яшьлек юбилеен каршылады. Кадерлебез, гаиләбезнең якты кояшы - тугры гомер юлдашым, сөекле әтиебез, газиз абыебыз һәм энебез!

Сине чын күңелебездән күркәм бәйрәмең белән котлыйбыз. Гомереңнең һәр мизгеле сиңа шатлык-куанычлар гына алып килсен! Бәйрәмең котлы, мөбәрәк, бәхетең һәрчак түгәрәк булсын. Алдагы көннәрдә дә әниебез белән бәхеткә, шатлыкка күмелеп, кайгы-хәсрәтләр күрми, озак еллар безне сөендереп яшәгез.Синең кебек киң күңелле, барчабызга да йөрәк җылысын мулдан биреп яшәүче әтиебез булу – безнең өчен зур бәхет. Рәхмәт сиңа барысы өчен дә!

Котлы булсын кадерлебез юбилеең,
Шатлык балкып торсын йөзеңдә.
Безнең өчен бик тә кадерле син,
Рәхмәт яусын барысы өчен дә.
Теләкләрнең кайсын теләсәк тә,
Аз булыр күк синең хөрмәткә.
Аяз булсын мәңге күңел күгең
Без калабыз шушы теләктә.

Ихлас күңелдән Сәкинә Заһидулловна, балаларың Равилә-Салиһҗан, Равил–Лена, Найлә-Рифкать, оныкларың Альбина-Руслан, Динара, Азат, Тимур, оныкчаң Булатик.

Яңа Яндука – Яңа Кулаткы – Ульяновск – Иске Кулаткы.

Иң кадерле, сөекле сеңелебез, апам Гөлнур Тәфиковна МУСИНА!

Без сине чын күңелдән юбилейлы туган көнең белән котлыйбыз. Сиңа нык исәнлек, озын гомер, тыныч тормыш, гаилә бәхете телибез. Безнең өчен һәрчак олы җанлы, киң күңелле булып калуың өчен мең рәхмәт сина. Кайгы-хәсрәт күрмичә, балаларыңның, якыннарыңның җан җылысын тоеп, озын-озак яшәвеңне телибез. Безне, якыннарыңны, һәрчак җылы сүз, ачык йөз белән шатланып каршы аласың. Синең белән очрашкач, сөйләшер сүзләребез дә бетмәс, төсле. Бүгенге көнгә кадәр безне кайгыртып, борчу-шатлыкларыбызны үзеңнекедәй күреп, һәрвакыт ярдәм итәргә ашкынып торасың. Рәхмәт сиңа барысы өчен дә! Аллаһы Тәгалә олыласын үзеңне.

Якты кояш һәрчак юлдаш булсын,
Шатлык тоеп типсен йөрәгең.
Авырлыклар сине урап үтсен,
Кабул булсын һәрбер теләгең.

Җылы теләкләр белән апаң Фәзилә, абыең Фатих, сеңелең Лилия гаиләләре белән.

Иске Атлаш – Балаково – Әләзән – Тольятти.

Карамалы авылында туып, үсеп, хәзерге вакытта Югары Терешка авылында гомер итүче Асия Камиловна РӘХМӘТУЛЛИНА 3 мартта 65 яшьлек юбилеен каршы ала.

Кадерлебез безнең! Шушындый зур һәм якты бәйрәмең көнендә без сиңа ихлас котлауларыбызны юллыйбыз. . Олы юбилеең мөбәрәк, ризык тулы өстәл өсте түгәрәк, гомер юлың сикәлтәсез һәм куанычлы булсын. Киләчәктә дә балаларыңның, оныкларыңның, туганнарыңның мәрхәмәтлелеген, җан җылысын тоеп, яшәвеңне телибез.

Ак бәхетләр алып килсен сиңа
Яз башында килгән пар кошлар.
Юбилеең котлы булсын диеп,
Җибәрәбез сиңа алкышлар.
Юлларыңа киртәләр очраса да,
Тирән упкыннарга юлыкма.
Һәрчак сиңа ярдәмгә килерлек
Туганнарың барын онытма.
Котлы булсын юбилеең
Газиз туган апабыз!
Исәнлек һәм ак бәхетләр
Сиңа теләп калабыз!

